**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

2021 елның 10 декабре
№ 2
Кодаш авылы, мәдәният йорты

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге составына керүче Кодаш авылы торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте:**

1. 2022 елда гражданнарның үзара салымын Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Кодаш авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган 1 төркем инвалидлардан, өч һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләрдән, вакытлы хезмәт хәрбиләреннән тыш, 300,00 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Кодаш т. п. капиталь төзекләндерү;
- Гомуми файдаланудагы автомобиль юлын ясалма яктырту урнаштыру (Кодаш ).

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге башлыгы Г. Ә. Хәйсарова**